| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **Приказ** | | **Боерык** |
| 28.06.2019 | г.Казань | № 185-од |

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар
буенча дәүләт комитеты каршындагы журналистларны
аккредитацияләү кагыйдәләрен раслау турында

«Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 48 статьясы нигезендә б о е р а м:

1. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты каршындагы журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләрен расларга.
2. Әлеге боерыкны законда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.
3. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны гомуми бүлекнең өлкән белгече К. К. Ванюковага йөкләргә.

Рәис Ф.С. Батков

Татарстан Республикасы
Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитетының
2019 елның 28 июненнән
185-од номерлы боерыгы
белән расланды

**Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты каршындагы журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләре**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге кагыйдәләр «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 48 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча Дәүләт комитеты каршындагы массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын аккредитацияләү тәртибен регламентлыйлар (алга таба-аккредитация, Дәүләт комитеты).

1.2. Аккредитация вакыт буенча чикләнми. Массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясе теләге буенча аккредитация конкрет редакция биремен үтәү өчен кирәк булган вакытка яки вакытлыча булмаган аккредитацияләнгән журналистны алмаштыру өчен башкарылырга мөмкин(вакытлы аккредитация).

## II. Аккредитация алу хокукы

2.1. Аккредитациягә милек формасына һәм оештыручылар составына бәйсез рәвештә, массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре, шул исәптән чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары да ия. Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистын аккредитацияләү өчен, аны Россия Федерациясе Чит ил эшләре министрлыгы каршындагы аккредитацияләүне раслау зарур.

## III. Аккредитация тәртибе

3.1. Аккредитация узу өчен гариза, Дәүләт комитетына массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясе җитәкчесе имзасы белән, Дәүләт комитеты тарафыннан күрсәтелгән гаризаны алу фактын, датасын һәм вакытын расларга мөмкинлек бирүче теләсә нинди ысул белән бирелә.

3.2. Гаризада журналистның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), аның вазыйфасы, эш һәм шәхси телефоннары, электрон почта адресы, массакүләм мәгълүмат чараларының тулы исеме, массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү турында таныклык датасы һәм номеры күрсәтелә.

Вакытлы аккредитациягә бирелгән гаризада шулай ук редакция йөкләмәсе һәм аны үтәү вакыты күрсәтелә, ә вакытлыча булмау сәбәпле, аккредитация узган

журналистны алмаштырганда- аның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) һәм алмаштыручы журналистның аккредитация срогы күрсәтелә.

Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистын аккредитацияләү өчен, өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Чит ил эшләре министрлыгы каршында аккредитацияне раслый торган документларның күчермәләре куела.

3.3. Әлеге Кагыйдәләрнең 3.2 пункты таләпләренә туры килми торган гаризалар каралмый.

3.4. Аккредитацияләү турында карар (аккредитацияләүдән баш тарту турында) гариза кергән көннән алып, ике эш көненнән дә соңга калмыйча, Дәүләт комитеты рәисе (аның вазыйфаларын үтәүче зат) (алга таба – рәис) тарафыннан кабул ителә. Мондый карар рәиснең тиешле боерык чыгарган көннән соң, икенче эш көненнән дә соңга калмыйча, редакция тарафыннан алу фактын, датасын һәм вакытын расларга мөмкинлек бирә торган теләсә кайсы ысул белән гариза җибәргән массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясенә җиткерелә.

3.5. Массакүләм мәгълүмат чаралары махсус характерда (реклама тарату, эротик басмалар) булса, аккредитацияләүдән баш тарталар.

3.6. Гаризаларны карау, аккредитация турында рәис боерыгы проектын әзерләү (аккредитацияләүдән баш тарту), шулай ук кабул ителгән карар турында массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясенә хәбәр итү, Дәүләт комитетының гомуми бүлегенең өлкән белгече тарафыннан, әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

## IV. Аккредитацияләнгән журналистларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Аккредитацияләнгән журналистлар киләсе хокукларга ия:

чарада катнашу;

Дәүләт комитетында булган, чара турында рәсми документларның күчермәләрен алу (көн тәртибе, матбугат релизлары, мәгълүмати-белешмә, статистик, аналитик һәм башка материаллар);

бастыру өчен билгеләнгән мәгълүмат-белешмә материаллар белән танышу;

Россия Федерациясе законнарында каралган башка хокуклар.

4.2. Аккредитацияләнгән журналистлар бурычлы:

чара регламентын үтәргә һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен махсус оештырылмаган очракта, аның барышына катышмаска;

чарада катнашучыларның эшчәнлегенә комачауламаска;

Дәүләт комитеты тарафыннан бирелгән матбугат релизларын, мәгълүмат-белешмә, статистик, аналитик һәм башка материалларны бастырып чыгарганда (эфирда сөйләгәндә), мәгълүмат чыганакларына сылтама ясарга;

үзенең һөнәри эшчәнлеген тормышка ашырганда, Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында дөрес булмаган мәгълүматлар таратмаска.

_______________________________